**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3305**
**01.07.2022**

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмә, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә чик тарифларны раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 8140 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                            Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 июлендәге
3305 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль учреждениеләре
тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләргә
чик тарифлар

| № т/б | Түләүле хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге (академик сәгать) | Чик тариф сумнарда, ӨКС исәпкә алмыйча |
|---|---|---|---|
| 1. | Гомуми белем бирү программалары буенча тирәнтен өйрәнү, мәктәпкәчә әзерлек | 1 сәгать[1] | 402,8 |
| 2. | Музыка сәнгате | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 3. | Фольклор сәнгате | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 4. | Эстрада-джаз сәнгате | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 5. | Хор сәнгате | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 6. | Хореография сәнгате | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 7. | Театр юнәлеше | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 8. | Гомуми эстетик үсеш | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 9. | Рәсем сәнгатенә өйрәтү | 1 сәгать [1] | 287,8 |
| 10. | Физкультура-спорт юнәлеше (физкультура-сәламәтләндерү дәресләре) | 1 сәгать [1] | 460,3 |
| 11. | Туризм-туган якны өйрәнү юнәлеше | 1 сәгать [1] | 172,6 |
| 12. | Экология-биология юнәлеше | 1 сәгать [1] | 172,6 |
| 13. | Социаль-педагогик юнәлеш | 1 сәгать [1] | 172,6 |
| 14. | Социаль-икътисадый юнәлеш | 1 сәгать [1] | 172,6 |
| 15. | Хәрби-патриотик юнәлеш | 1 сәгать [1] | 172,6 |
| 16. | Сөйләм һәм танып белү эшчәнлеген үстерү буенча коррекция-үсеш дәресләре | 1 сәгать [2] | 680,2 |
| 17. | Барлык юнәлешләр буенча индивидуаль дәресләр | 1 сәгать [2] | 1 150,2 |
| 18. | Һөнәри әзерлек программалары | 1 сәгать [1] | 517,9 |

<1> төркемдәге бер кешегә тариф.
<2> индивидуаль дәресләргә тариф.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева